СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

12.12.2019 Баулы шәһәре № 239

Бюджет ссудалары буенча
бурычларны исәптән төшерү турында

Баулы муниципаль районы Советының «Баулы муниципаль районы бюджеты алдында авыл хуҗалыгы һәм хезмәт күрсәтүче оешмаларның бурычларын реструктуризацияләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 19 сентябрендәге 123 номерлы карары (Баулы муниципаль районы Советының 2008 елның 9 декабрендәге 194 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Татарстан Республикасы Арбитраж судының 2019 елның 22 августындагы А65-9253/2017 номерлы эше һәм «Колос» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативына (ИНН 1611000817) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган белешмәләр нигезендә Баулы муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2019 елның 1 ноябренә «Колос» авыл хуҗалыгы җитештерү кооперативын (ИНН 1611000817) бетерүгә бәйле рәвештә түләү чыганаклары булмаган 963 379 сум күләмендәге бюджет ссудалары буенча бурычны исәптән төшерергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны бюджет һәм финанс мәсьәләләре буенча Баулы муниципаль районы Советының даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе Р.Х. Гатиятуллин